БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» 06 2026 ел № 196

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турында» 2014 елның 27 мартындагы 162 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турындагы Нигезләмәгә (2015 елның 3февралендәге 57 номерлы, 2018 елның 26 гыйнварендагы 46 номерлы, 2019 елның 28 мартындагы 143 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 4.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.15. Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны иртә ачыклау максатларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрү. Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрү тәртибе гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен төзү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкара торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов